134

# Россия гражданнары, энеләр һәм сеңелләр!

Без сезгә илебезнең соңгы нигезләрен тетрәткән чиктән тыш бәла йорт бусагаларыбызга килеп җиткән сәгатьтә мөрәҗәгать итәбез. Безнең Туган илебезгә, көчле халкыбызга ни булды соң?

Моңа кадәр күрелмәгән рус цивилизациясен тудырып, без еллар буена җыйган, киләчәк өчен дип төзегән нәрсәләр бер дигәндә таланып бетелде. Бер төркем юлбасарлар тукталган заводлар, үлеп баручы флотлар һәм армияләр, чүп үлән үсүче кырлар урынында үзләренә сарайлар һәм төнге клублар төзеделәр. Игенче һәм төзүче дә түгел, сугышчан офицер белән мулла да түгел, язучы һәм уйлап табучы да түгел, ә киллер белән сутенер «заман геройлары»на әйләнделәр. Яклаудан мәхрүм ителгән, җитешлелеген һәм ышанычын югалткан халык үлеп бетеп бара. Рәсәй ел саен үзенең миллион халкын югалта. Туймас һәм талаучы реформаларны халык белән туйдыралар. Моның белән килешербезме соң?

Бүгенге власть—черегән түрәләр, обком һәм министрлыклар убырлары, күләгә икътисады гангстерлары йомгагы ул. Бу власть белән бергә—милли телевидениене һәм матбугатны оккупацияләгән басып алучылар төркеме. Алар бертуктамый халык аңында рәхимсез операция алып баралар, талантлы һәм эшкә сәләтле халыкны гарипкә, азгынга, томанага әйләндерергә тырышалар. Шунда да дәшмәбезме?

Юк, халык эндәшми түгел. Халык тавышын күтәрә. Ел саен, забастовкадан забастовкага, протесттан протестка, сайлаулардан сайлауларга кадәр. Без буйсынмас халык-патриотик оппозициясенә тупландык, аклар белән кызылларга да, бай белән ярлыга да, дингә ышанучы һәм ышанмаучыларга да бүленмибез. Без Рәсәй дәүләте кешеләре—төзүчеләр һәм иген игүчеләр, сәүдә хезмәткәрләре һәм руханилар, солдатлар һәм рәссамнар,—без үзебезнең дәгъвалардан, иске, тарихка кереп баручы бәхәсләрдән, үзара үпкә һәм шелтәләрдән баш тарттык. Рәсәй бәласе, храм һәм гарнизоннарыбызга, бала бишекләренә һәм бабаларыбыз каберләренә янау—безне менә нәрсә берләштерде. Утыз миллион Рәсәй гражданнары безгә һәм лидерыбыз Г. А. Зюгановка соңгы сайлауларда үз тавышларын бирделәр. Һәм көн саен без арта барабыз.

Власть безнең лозунгларны, максатларны бозып күрсәтә. Безне акылга каты, кайгылы үткәнне сагынучылар, киләчәкне күрәлмаучылар итеп тасвирлый. Безне ГУЛАГ сөякләре, гражданнар сугышы көле белән күмәләр, вөҗдан ирегеn буучылар итеп күрсәтәләр. Ләкин бу бездән куркудан килә. Чөнки патша офицерларын атучы, рус крестьяннарын раскулачить итүчеләр, архимандритлар һәм руханилар төялгән баржаны батыручылар нәселе безнең түгел, аларның сафларында. Алар сафларында—әле кайчан гына безне үле һәм көлке догмаларга ышанырга мәҗбүр итүче идеологик ялганчылар. Алар хәзер дә элеккечә үк идарә итәләр, ялганлыйлар, көчлиләр.

Без — киләчәк, рус цивилизациясенең череклеге һәм торгынлыгы аша үтеп кергән көчле, Рәсәйне чәчәк атучы һәм җиңелмәс итеп күз алдына китерүче,

безнең галимнәр тарафыннан ясалган, ләкин власть тырышлыгы белән оныттылган һәм тапталган ачышлар турында өмет итүче цивилизация вәкилләре. Без халыкның ирекка һәм без барлыкка китергән культурада, хәзер власть ихтыяры белән туктатылган һәм ябылган космик һәм глобаль проектларда гәүдәләндерелгән иҗатка булган омтылышын чагылдырабыз. Без җан һәм интеллект серләренә ия булырга омтылабыз, Алланы (Ходайны) кешедә, материядә эзлибез, табигатькә дини караш уятабыз. Без—әле күптән түгел генә чүлдә уникаль шәһәрләр төзүчеләр, дөнья сугыш коралына тигезлек (паритет) билгеләүчеләр. Һәм без дөньяда башкача югослав һәм чечен сугышлары булмавына, һәрберсенең кабатланмас язмышы булган барлык халыкларның, планетаның чикле ресурсларын төрле бәхәсләргә исраф итмичә, галәм союзына берләшүләренә ирешәчәкбез. Илебезнең җимерек промышленносте һәм культурасындагы безгә көчләп тагылган йончыткыч ызгышлар безгә киләчәк турында уйларга комачауламый. Рәсәйне 300 елга артка ташлаган халыкны кыргыйланырга мәҗбүр иткән бүгенге кремль феодаллары түгел,—Рәсәйнең киләчәген гәүдәләндерүчеләр—без.

Оятсыз власть безне ничек кенә каралтырга тырышмый да, нинди генә бәлаләр якмый! Имеш, без кешеләрнең фатирларын һәм кибетләрен, дача участокларын һәм алмашу пунктларын тартып алырга телибез. Имеш, без хосусый парикмахерскаялар, кибетләргә һәм коммерция банкларына каршы. Ялганчыларга ышанмагыз! Киресенчә, без җир хуҗаларына, әгәр эшкәртергә хәлләреннән килә икән, җирләрен арттырачакбыз. Безшәхси фатирларны—талаучыдан, хосусый кибетне рэкетирлардан коткарачакбыз. Без рус коммерция банкын чит ил банкыннан яклаячакбыз. Бары тик акча һәм хезмәт, зирәклек һәм хәстәрлелек, хосусый милекне баектырып, Туган илне дә баетсыннар, җимереклек һәм ач үлемгә генә китермәсеннәр.

БДБ илләренә танклар җибәреп, җиңелгән территорияләрне штыклар белән үзебезгә кушалар дип безнең белән халыкны куркыталар. Ялганчыларга ышанмагыз!

Безгә сүз иреген тыячаклар, храмнарны һәм мәчетләрне ябачаклар, дип бәла ягалар. Яла ягучыларга ышанмагыз!

Безнең арада руханилар һәм мөфтиләр дә бар, без чиркәүләрдә һәм мәчетләрдә гыйбадәт кылабыз. Һәм үзебезнең изге нәрсәләребезне чит ил мәсхәрә итүчеләреннән һәм сектантлардан яклаячакбыз. Телевидение тапшырулары аша без авыл, фабрика поселокларындагы, фәнни лабораторияләрдәге тормыш турында беләчәкбез, Кремльдәге агулы гайбәтләрне, башкала дөньясындагы интригаларны карап интекмәячәкбез.

Безне экстремистлар һәм боевиклар, Кремльне көч белән басып алырга теләүчеләр дип атыйлар. Яманлаучыларга ышанмагыз! Өч ел элек Конституцияне без таптамадык, пулеметлардан халыкка без атмадык һәм кешелек күз алдында үз парламентыбызга без ут төртмәдек. Без—закон турында кайгыртучылар, безгә гражданнар тынычлыгы кадерле, һәм властька таба без халыкның иреге буенча хәрәкәт итәбез. Нәкъ шулай, законлы төстә, сайлаулар аша, без властька керәчәкбез.

Без, «Россия Халык-патриотик союзы», илебезгә явызлык теләмәүче һәр кеше өчен ачыкбыз. Без сезгә мөрәҗәгать итәбез—«Россия. Ватан. Халык!» дип язылган безнең байрак астына басыгыз!

(«Россия Халык-патриотик союзы»—НПСР мөрәҗәгатеннән, август, 1996).